ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2022 г.Лениногорск №108

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре шәһәр төзелеше зоналары картасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналары картасына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлауларда фикер алышу нәтиҗәләрен карап тикшергәннән соң, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Лениногорск шәһәре, Җиңүнең 50 еллыгы пр-кт адресы буенча урнашкан, 22,16:51:010501:5189 һәм 16:51:010501:5426 кадастр номерлары булган җир кишәрлекләренә карата, якын-тирә йортлар өчен парковка урыннары оештыру максатыннан, Д1 территориаль зонасын (эшлекле, иҗтимагый һәм коммерцияле билгеләнештәге зонаны) һәм ИТЗ (инженерлык инфраструктурасы объектлары зонасын) ТОП территориаль зонасына (гомуми файдаланудагы территория) үзгәртү буенча үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең Лениногорск шәһәр

Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Лениногорск шәһәре, Җиңүнең 50 еллыгы пр-кт адресы буенча урнашкан, 16:51:012401:1201 кадастр номеры булган җир кишәрлекләренә карата, киләчәктә торак булмаган биналарның һәм биналарның билгеләнешен үзгәртү максатында, 4 территориаль зонасын (транспорт инфраструктурасы объектлары зонасы) Д1 территориаль зонасына (эшлекле, җәмәгать һәм коммерция билгеләнешендәге зонага) үзгәртү буенча үзгәреш кертергә.

3.Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналары картасына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә һәм яңартылган документларны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Россия Федерациясе территориаль планлаштыру Федераль геомәгълүмат системасында (ФГИС РТ) урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында http://Leninogorsk.tatar.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р. Сытдиковка йөкләргә.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов